ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**20.12.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 4112**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 19 августындагы 989 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы карары үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 506 номерлы, 2022 елның 18 октябрендәге 2765 номерлы, 2023 елның 26 гыйнварындагы 105 номерлы, 2023 елның 30 июнендәге 1923 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (1 нче кушымта):

VIII бүлектә:

исемендә «һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 10 - 12 пунктлар өстәргә:

"10. Балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи окладды түбәндәге формула $\left(O_{d_s}\right)$ буенча

исәпләнә:

$$O_{d_s} = O_{b_s} \times S,$$

биредә:

$O_{b_s}$ - һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесенең база окладлы күләме 18 398 сум күләмендә билгеләнә;

S-асылда эшләнгән вакыт (ставкасы).

11. Хезмәтнең интенсивлыгы өчен түләүләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесенә бирелә һәм $\left(B_{sr_s}\right)$ түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{sr_s} = O_{d_s} \times D_{sr_s},$$

биредә:

$O_{d_s}$ - һәм балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесенең вазыйфаи окладлы күләме;

$D_{sr_s}$ - балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе хезмәте интенсивлыгы өчен өстәмәләр күләме 100 процентка тигез дип кабул ителә.

12. Балалар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү һәм тәрбия буенча директор киңәшчесе өчен компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.";

1.2.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (1 нче кушымта):

әлеге карар белән расланган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәдәге 5 нче таблицаның 1 нче графасында «Техник укыту бүлекләре (бюролары), җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре» юлындагы «министрлыкларның (ведомстволарның)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга.

1.3.«Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (2 нче кушымта):

әлеге карар белән расланган Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдәге 4 нче таблицаның 1 нче графасында «Техник укыту бүлекләре (бюролары), җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның

(ведомстволарның) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре» юлындагы «министрлыкларның (ведомстволарның)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга.

1.4.Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (3 нче кушымта):

әлеге карар белән расланган Зеленодольск муниципаль районы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдәге 3 нче таблицаның 1 нче графасында «Техник укыту бүлекләре (бюролары), җитештерүдә кадрлар әзерләү һәм квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче оешмаларның, министрлыкларның (ведомстволарның) бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре» юлындагы «министрлыкларның (ведомстволарның)» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга.

2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Әлеге карарның 1.1 пунктчасының гамәлдә булуы 2023 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин